# КАРАР

## Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

№ 201-30 22 август 2018 ел

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы территориясендә урнашкан күпфатирлы
йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда
кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет
акчасы исәбеннән кире кайтарылу һәм (яки) кире кайтарылу
рәвешендә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының
исемлеген һәм тәртибен раслау турында"
2007 ел, 28нче июль, 346нчы номерлы карары

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында "1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 20 декабрендәге 399-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә»

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчасы исәбеннән кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының исемлеген һәм тәртибен раслау турында" 2011 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары, беренче номерлы кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны “ Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзөстемдә калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Азнакай районы Советы карарына
2018 елның 22 августы, 201-30

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә кире кайтарыла һәм (яки) кире кайтармый торган нигездә "Җирле бюджет акчасы хисабына, кичектергесез ихтыяҗ туганда, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда өстәмә ярдәм күрсәтү тәртибе һәм  ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге турында" 2009 ел, 30 апрель, 279 нчы карары

I. Гомуми нигезләмәләр (положенияләр)

1. Әлеге  нигезләмә, кире кайтарыла һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда, кичектергесез ихтыяҗ туганда өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге һәм тәртибе (алга таба – Тәртип), Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясындагы 9.3 пункты нигезендә эшләнгән һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру буенча кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган очраклар исемлеген һәм кичектергесез чаралар күрү өчен җирле бюджет акчасы хисабына  өстәмә ярдәм күрсәтү процедурасын билгели.

2. Әлеге карар Азнакай муниципаль районы территориясе, шул исәптән Азнакай шәһәрендә, шәһәр тибындагы Актүбә  поселогында, Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләрендә  урнашкан күпфатирлы йортларга кагыла.

3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда җирле бюджет акчалары хисабына кире кайтарылу һәм (яки) кире кайтарылу нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары Исемлеге үз эченә ала:
- янгыннар һәм шартлаулар;
- биналар һәм корылмаларның  кинәт җимерелүе;
- электр энергеясы системаларында аварияләр;
- тормышны тәэмин итү коммуналь системаларында авария, гидродинамик аварияләр;
- куркыныч геологик күренешләр;
- куркыныч метеорологик күренешләр;
- куркыныч гидрологик күренешләр;
- табигый янгыннар;
- зур террорчылык актлары.

4. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кичектергесез ихтыяҗ туганда кире кайтарыла һәм (яисә) кире кайтарылмый троган нигездә өстәмә ярдәм, җирле бюджет акчалары исәбеннән, җирле үзидарә органына бирелә.

5. Җирле бюджет акчасы хисабына кире кайтарыла һәм (яки) кире кайтарылмый торган нигездә күпфатирлы йортларда, гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ туганда, өстәмә ярдәм күрсәтү турында Карар Азнакай район Советы карары белән раслана.

6. Карар кабул итү өчен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты бина милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның мөрәҗәгате нигезендә, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән очрак барлыкка килгән көннән алып 30 календарь көн эчендә, түбәндәге документлар белән Азнакай район Советына капиталь ремонт үткәрү кирәклеге турында мәгълүмат бирә:
- капиталь ремонт үткәрү мәсьәләсе хәл ителә торган күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтенең техник торышы турында мәгълүмат туплау;
- дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру, норматив-хокукый җайга салу, шулай ук гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү, гадәттән тыш хәл очрагын тану функцияләрен гамәлгә ашыра торган органның карары;
- капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге;
- капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүгә (яки) эшләр башкаруга чыгымнар сметасы.

7. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге Тәртипнең 5 пунктына карап туплаган мәгълүматы нигезендә, Азнакай район Советы күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеген, капиталь ремонт һәм аны финанслау чыганакларын раслау турында карар проектын эшли.

8. Капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында " 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган тәртип нигезендә үтәлә.